**(Ахыры. Башы 38, 39 нчы саннарда).**

Томскига Екатеринбургтагы “Агафуровлар йорты” музей-клубы мөдире Лариса Конавалова да килгән иде. Ул төбәк тарихын өйрәнүчеләргә “Сәүдәгәр Агафуровлар – милли үзара-бәйләнеш мәктәбе” турында сөйләде. Үзенең чыгышы белән данлы милләттәшләр белән горурлану хисен көчәйтеп җибәрде.

Гаилә башлыгы Хисаметдин Гафур улы Агафуров хәзерге Лаеш районының Кече Елга авылыннан булган икән. 1831 елгы. Крестьян баласы Екатеринбургка солдат хезмәтенә килгән. Унтер-офицер дәрәҗәсендә отставкага чыккач, сәүдә белән шөгыльләнә башлаган. Хатыны Бибигазизә белән Камалетдин (1853-1922), Зәйнетдин (1861-1924), Кашафетдин (1871-1935)






● Агафуровлар йорты.

# ӨЧ ТУКТАЛЫШ

## 3. ЕКАТЕРИНБУРГТА

исемле уллар үстергән. “Бертуган Агафуровлар сәүдә йорты”н оештырган. 2 нче гильдия сәүдәгәр булып киткән. Кибетләре Екатеринбургта, Пермьдә, Төмәндә, Мәскәүдә, Польшадагы Варшавада, Кытай шәһәрләрендә эшли. Эрбет ярминкәсендә дә сәүдә итә. Анда азык-төлек, кием-салым, хуҗалык кирәк-яраклары тәкъдим ителә. Сатып алучыларны бәя төшереп кызыктыралар. Сатучыларны чәчтараш чакырып матурлаталар, үзләренең шәхси дачаларына ялга җибәреп күңелләрен күрәләр. Хезмәткәрләренә, премия урынына, велосипед бүләк итәләр. Моны башкалар күрә, ике көпчәкле транспорт белән кызыксыну арта. Нәтиҗәдә велодром төзелә, ярышлар башлана.



● Һәр якның үз матурлыгы.

Агафуровларның 1896-1898 елларда төзелгән, бүгенге адресы Сакко һәм Ванцетти урамындагы, 28 номерлы ике катлы, челтәрле-бизәкле агач йортларына да күпләр сокланып карый. Әмма совет хакимияте урнашкач, аларга большевикларның күзе төшә, затлы тораклар хуҗаларыннан тартып алына. Аерым бүлмәләр, коммуналь фатир итеп, мохтаҗларга бирелә. Байтак еллар үткәч кенә сәүдәгәр Агафуровлар йорты О.Клер исемендәге Свердловск өлкәсе музее филиалына-клубына әйләнә. Монда төрле һөнәр ияләре кул эшләре белән шөгыльләнә, шул җирлектә бихисап күргәзмәләр оештырыла. Сәяхәтчеләргә исә күз явын алырлык затлы өй хуҗалары турында кыскача мәгълүмат бирелә. Тик монда, берничә дистә фоторәсемнән кала, Агафуровларның шәхси әйберләре юк. Шулай ук сәүдәгәрләрнең сату-алу тарихы да җентекләп өйрәнелмәгән. Күз явын алырлык дачалар язмышы да билгесезлектә кала. Җирле тарихчыларны, нигәдер, татар сәүдәгәрләре Агафуровлар тормышы кызыксындырмый. Югыйсә, шундый йорт салып калдырган өчен рәхмәт йөзеннән, Агафуровларга күптән йөз белән борылырга вакыт бит инде. Чынлыкта исә Агафуров фамилиясенең килеп чыгышы бүгенгә кадәр сер булып кала. “Ни өчен ул Гафуров түгел”, – дигән сорауга экскурсоводлар төгәл җавап бирә алмый.


Аларның икенче йортлары да янәшәдә генә урын алып тора. Сакко һәм Ванцетти урамындагы 24 нче “Сәүдәгәр Агафуровлар йорты” архитектура һәйкәле итеп танылды. Истәлек тактасында гаҗәеп корылманың 1895 елда архитектура академигы Юлиан Дютель тарафыннан төзелүе хәбәр ителә. Әлеге бина 1987 елда төзекләндерелә, дәүләт тарафыннан саклана. Бирегә ТР Президенты Указы белән 1996 елда оешкан Татарстан Республикасының Урал төбәгендәге вәкиллеге урнаша. Чөнки Екатеринбургтагы – 46232, өлкәдәге 143803 милләттәш мондый кайгыртучанлыкка лаек. Әмма ике катлы затлы бинаның бояулары купшыну, төссезләнүе генә кәефне төшерә. Казандагы консуллыклар балкып торганда, Екатеринбургтагы Татарстан илчелеген болай мескен хәлгә төшерү бер дә килешми.

Екатеринбург татарлары тормышының тарихи белешмәсенә килгәндә, вәкаләтле вәкил Хәйдәр Гыйльфанов үткәндәге хәлләр белән бик җентекләп таныштыра. Телгә алынган “Бертуган Агафуровлар” сәүдә йорты, мәсәлән, 1884 елдан 1919 елга кадәр гамәлдә була. Матбугатта беренче тапкыр 1889 елда искә төшерелгән гыйбадәтханә, мәдрәсә (1895), “Ф.Богатиев һәм уллары ширкәте” сәүдә фирмасы (ХХ гасыр башы), мөселман хәйрия җәмгыяте (1907 елда оеша, 1913 елда теркәлә), мөселман хатын-кызлары училищесы (1919), бушлай мөселман–рус китапханәсенең уку залы (1915), сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча вакытлыча мөселман комитеты (1917), шулай ук, 1919 елдан юкка чыга. Әмма индустриализация вакытында, 1919-1940 елларда, Екатеринбургка эшкә килгән татарлар тормышында кабат милли үсеш күтәрелеп ала. Калада М.Вахитов исемендәге клуб, берничә башлангыч татар мәктәбе һәм җидееллык белем йорты, Свердловск татар күчмә театры, Свердловск педагогика институты каршында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ишекләре ачыла. Төрле вакытта Төрки халыклар мәгарифе гамәли институты, Урал төрки халыклар педагогика институты эшли. “Социализм юлы”, “Сабан һәм чүкеч” газеталары, “Шәпи агай” юмор журналы һ.б. милли басмалар чыга. Радио татарча сөйләп тора. Тик тора-бара, совет хакимияте төрле милләтләр яшәешен онытып җибәргәч, төп игътибарын русларга юнәлткәч, ирешелгән казанышлар тагын кыелып төшә. Шәһәрнең татар мөселман җәмгыяте эшчәнлеге көпшәкләнеп кала.

Әмма арадан булдыклы милләттәшләребез, асфальт астыннан бәреп чыккан яшел үсенте шикелле, татар иҗтимагый тормышын җанландырырга да талпынып карый. Россия Юстиция министрлыгы мәгълүматына караганда, бүгенге көндә Свердловск өлкәсендә рәсми рәвештә 10 татар оешмасы теркәлә. Мәгариф өлкәсендә дә татар телен югалтмас өчен тартышучылар күренә. Татар авылларында 24 клуб эшли. 44 китапханәнең киштәләре татарча китаплар белән тулылана. Айга бер мәртәбә 8 сәхифәле “Саф чишмә” газетасы 1500 данәдә тарала. “Урал татарлары” сайты ай саен 8-9 мең кызыксынучыны үзенә җәлеп итә. “Татарстан – Яңа гасыр” ширкәтенең Екатеринбургтагы хәбәрче пункты айга 28 телевизион яңалыкны, 4 күзәтүне, 6 радиосюжетны караучыларга һәм тыңлаучыларга җиткерә. Татар милли спорт төрләрен үстерүгә дә йөз тотыла. Физик культура һәм спорт министрлыгында 1998 елдан татарча көрәш федерациясе эшли. Ул ел саен “Урал кубогы” һәм Советлар Союзы Герое Н.Хәҗипов истәлегенә хәтер турниры үткәрә. Сабан туенда ат чабышында катнашучылар күбәя. 2015 елдан “Ак барс” хоккей клубы призына Свердловск, Чиләбе өлкәләре, Пермь крае, Татарстан һәм Башкортстан Республикасы яшүсмерләре ярыша...

# Мосафир сәфәрдән кайтты





● Татар сәүдәгәрләре.




● 1879 елгы зират.



● Монда байлар яшәгән.



● Шәһәр уртасында – агач өй.



● Челтәрле дә бизәкле...

Уңышларны-табышларны искә төшергәндә, тимер юл вокзалыннан ерак түгел, Артинская урамындагы 16 нчы йортта урнашкан “Сабантуй” караоке клубы, кафесы да мактап телгә алына. Заманында ул Дагстанның эшлекле егетләре кулында була. 7 ел элек әлеге ике катлы бинаны электроника белгече Азат Ризванов арендага ала. Нәсел шәҗәрәсе әтисе Финат ягыннан – Башкортстанның Балтач авылына, әнисе Шәмсия тарафыннан Кукмараның Сәрдекбашына ялганган булдыклы милләттәш аны ял үзәгенә әйләндерә. “Сабантуй” исеменә тиңдәш булу өчен, диварга мәйдан рәсемен, көрәш, аркан тартышу, капчык белән сугышу кебек уеннарның күренешләрен ясата. Заманында музыка мәктәбендә укып, әтисе кебек баянда уйнап сәнгать әһелләренә якынайган Азат Екатеринбургта чыгыш ясаган татар артистларының сурәтләренә дә урын таба. Игъланнар тактасында булачак яңа концертлар турындагы хәбәрләрне дә даими рәвештә урнаштыра. Милли музыка агылып торган залда җомга-шимбә көннәрендә, 200 ләп милләттәшкә татар дискотекалары оештыра. Милли аш-су белән сыйлап, монда танышкан яшьләрнең туйларын үткәрә. Электроника белгече буларак, төрле җайланмаларны төзәтүдә ярдәм сорап килүчеләрне дә борып чыгармый.

Соңгы вакытта “Уралның мөселман учагы” оешмасы да телдән төшми. Аңа төзүче – эшкуар, шәхси иминият ширкәте хуҗасы Илдар Хәбибуллин җитәкчелек итә. “XIX гасырның 80-90 нчы елларыннан 1919 елга кадәр милли-мөселман, 1919 елдан 1942 елга кадәр татар-башкорт кварталы булып йөргән бистә Усольцевская-Коковинская-Студеная урамнары өчпочмагында урнаша, - дип аңлатма бирә ул. – Әлеге урамнарның заманча аталышы: Сакко һәм Ванцетти – Шейнкман – Жуков. Бу тирәлеккә беренче булып 1882 елда Агафуровлар күз сала. Биредә татар байлары Богатиевлар, Әбдерәшитовлар зур төзелеш алып бара. Алар тирәсенә башка татарлар һәм башкортлар елыша.

Шейнкман урамындагы 18 нче йорт, 1917 елгы Бөек октябрь революциясеннән соң, Екатеринбург шәһәренең татар мөселман җәмгыятенә бирелә. Монда “Урал учагы” мөселман театры урнаша, драма түгәрәге эшли, башка мәдәният оешмалары сыену урыны таба. 1922 елда, өч бүлмәдән тыш, татар-башкорт театры түбәндәге һәм өстәге катны алып тора. 1932 елда биредә милли азчылык клубы, татар-башкорт китапханәсе урнаша. 1997 елда, Свердловск өлкәсе хөкүмәте карары нигезендә, әлеге бина төбәкнең мөселман Диния нәзарәте карамагына тәзекләндерү һәм файдалану өчен бирелде. 2019 елда, хөкүмәт һәм мөселман Диния нәзарәте килешүе буенча, мәдәни мирас объектын фәнни проект документациясе нигезендә торгызу бурычы куелды. Шул уңайдан, Екатеринбург һәм Свердловск өлкәсе мөселманнарыннан, бабаларыбызның эшкуарлык традицияләренә теләктәшлек күрсәтүләре, Мәдәни-мәгариф үзәген торгызуда хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәтүләре сорала. Агафуров, Богатиев, Әбдерәшитев һәм башкаларның мәдәни мирасы яклауга – саклауга мохтаҗ. 2023 елда әлеге Татар бистәсе сәяхәтчеләрне кабул итәрлек булсын иде!”

Зур эшкә алынган И.Хәбибуллин хыялларны халыкка җиткерүдә, чынга ашыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ярдәменә дә өметләнә.

Үз йөзе, матурлыгы булган Екатеринбург каласында бүгенге көндә шәһәрне тагын да бизәрлек Җәмигъ мәчете юк. Чөнки моңа җир күптән бүлеп бирелсә дә, анда нигез ташлары сугу, төзелеш алып бару сузылган. Йоклап йөргәч, федерация карамагындагы кишәрлек тартып алынган. Монда зур боз сарае төзелеше башланган. Ә гыйбадәтханә өчен яңа мәйдан шәһәр читендә – Сортировка бистәсендә бирелгән. Әмма урындагы хакимият аны рәсмиләштерергә ашыкмый. Шунлыктан Корбан, Ураза гаете кебек дини бәйрәмнәрдә намаз уку урамда дәвам итә. Түрәләр моны күреп тора, әмма ярдәм күрсәтергә ашыкмый.

Әңгәмәләшүгә кушылган тарихчы һәм язучы Фәүзия Бәйрәмова өлкәдәге 40 тан артык татар авылыннан фәкать икесенең генә тарихы язылуны әйтә. Бу бик аз. Шулай ук Татар бистәләре тарихы да өйрәнелмәгән. Эрбет ярминкәсендәге татар сәүдәгәрләрен, өйләрен, мәчетен дә искә төшерәсе бар. Архивтагы Тау идарәсе фонды да милләттәшләргә кагылышлы мәгълүматларны өйрәнүчене юксына. Мондагы документларның байтагы иске славян хәрефе белән язылган. Аларны укый белү, күчермәләрнең һәр бите өчен 300 сум түләү сорала. Ф.Бәйрәмова искәрткәнчә, халык санын искәкә алу вакыты якынлашуны онытмыйча, тарихчыларга эшне җиң сызганып башлап җибәрергә кирәк.

Репин урамы – 42 адресы буенча 1879 елда ачылган, даими вәкиллектән дүрт чакрым ераклыкта урнашкан татар зиратындагы зур кабер ташларны исәпкә алуны да кичектерергә ярамый. Чөнки аларның язулары тоныкланган, шуңа күрә гарәп хәрефләре белән уелган сүзләрне укып, тарих өчен фотога төшереп калырга кирәк. Алты гектарлы мәйданга сукбайлар ияләшкәнлектән, чардуганнарга да югалу, тимер-томырга тапшырылу куркынычы яный. Шәһәр уртасында калган каберлекнең бер ягында күп катлы йортлар да күтәрелә. Әгәр күз-колак булмасаң, тиздән йорт салып акча эшләүне максат итеп куйган төзүчеләрнең каберләрне ботарлавын көт тә тор. Моңа юл куймас һәм зиратны ташландык хәлгә калдырмас өчен, соңгы вакытта чистарту өмәләре үткәрү гадәткә керә. Иминият ширкәте җитәкчесе Илдар Хәбибуллин, Свердловский өлкәсе татар конгрессы рәисе Вәгыйс Имашев, Диния нәзарәтенең Урал мөхтәсибәте хезмәткәре Ринат Каштанов җитәкчелегендә тирәлек куаклардан, чүп-чардан чистартыла. Капка янында намаз уку бинасы төзелә башлый. Инде хәзер һәрбер ташбилгене теркәү мәслихәт. Тик калада моны булдырырлык белгечләр табылмый. Татарстан башкаласы Казаннан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре килү көтелә.

Татарстан Республикасының татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе Альберт Борһанов 2020-2021 елларда Екатеринбургта һәм Свердловск өлкәсендәге авылларда тарихчылар җыенын үткәрергә дә ниятли. Әлеге тәкъдимне вәкаләтле вәкил Хәйдәр Гыйлфанов та хуплый. Инде башланган эшнең дәвамлы һәм нәтиҗәле булуын телисе генә кала.

**Хәмзә БӘДРЕТДИНОВ.**
Казан-Екатеринбург-Казан.

**Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН**
фотолары.